**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«25» 09 2023 ел №3125

Борды авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Тукай муниципаль районы Уставына, Борды авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2023 елның 20 сентябрендәге халык тыңлаулар беркетмәсенә, Борды авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2023 елның 20 сентябрендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘ**

1. "Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ тарафыннан эшләнгән һәм 2023 елның 20 сентябрендә Борды авылында халык тыңлауларында каралган Борды авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты белән килешергә.
2. Борды авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын халык тыңлаулар беркетмәсе һәм халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә белән Тукай муниципаль районы Советына раслауга җибәрергә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин